МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

26.08.2019 г. Казань № 2572-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының $24^{18}$ статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы буенча Росреестр идарәсе каршындагы кадастр бәясен билгеләү нәтиҗәләре турында бәхәсләрне карау комиссиясенең 2019 ел, 24 май № 164 карары нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карары (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 ел, 13 февраль, № 279-р, 2017 ел, 21 апрель, № 894-р, 2017 ел, 23 июнь, № 1388-р, 2017 ел, 22 август, № 1923-р, 2017 ел, 26 сентябрь, № 2174-р, 2018 ел, 15 февраль, № 366-р, 2018 ел, 8 июнь, № 1588-р, 2018 ел, 6 август, № 2301-р, 2018 ел, 25 сентябрь, № 3152-р, 2018 ел, 14 ноябрь, № 3817-р, 2019 ел, 04 февраль, № 226-р, 2019 ел, 28

март, № 903-р, 2019 ел, 26 июнь, 1988-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), 2014 елның 1 гыйнварында булган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләренә дөреслеккә туры килмәү аркасында, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Күчемсез милек объектларының кадастр бәясе» бүлегендә:

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге» бүлекчәсендә:

76851 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «76851 | 16:50:011810:162 | 14114111,6». |

2. «Дәүләт теркәү, кадастр һәм картография федераль хезмәте федераль кадастр палатасы» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына күчемсез милек объектларының кадастр бәясе үзгәрүе турында тиешле тәртиптә белешмә кертергә тәкъдим итергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**